ZAMAN
ЗАМАН
ТАТАРСТАН

"ТЕЛДӘ, ФИКЕРДӘ, ЭШТӘ БЕРЛЕК"
И.Гаспралы

ХАЛЫКАРА ИҖТИМАГЫЙ - МӘДӘНИ ГӘЗИТ

№ 7 1—15 август 1993 ел Бәясе 5 сум

Баш мөхәррир сүзе

Төрек рухының көзгесе

ЭЛЕГРӘК вәгъдә иткәнчә, тәзитебезнең шушы саныннан без сезне төрек әдәбияты үрнәкләре белән таныштыра башлыйбыз.

Әдәбият тере яки бу халыкның үткәнен һәм бүгенен, аның хәлык-фигылен, төрле сыйфатларын, тәмәелләрен һәм үй-хыялларын тирән чагылдыра. Күренекле фикер ияләре кат-кат искәрткәнчә, әдәбият ул халыкның аны тәүдәләнеше, аның рухи тормышы сулышы һәм жимеше булып тора. Бу фикерне төрек әдәбияты казанышлары да раслый. Төркияне һәм төрек халкын дөрес һәм ачык күзаллау өчен, аның күренекле язучыларын ижаты белән танышу кирәк.

Сыйныфый көрәш, идеологик капма-каршылык, аннан да битәр, совет (асылда — урыс) империализмы үтет-нәсихәте безгә 70 ел буе Төркиянең начар якларын гына таныткырга омтылды. Миллионнарча төрки прекесез яшәгән илдә бердәнбер бәйсез төрки дәүләтнең абруен төшерү, шул рәвешле аның рухландыру, өметләндерү тылсымын, үзенә тарту көчен юкка чыгару аеруча әһәмиятле булгандыр, күрәсең. Әмма шул карангы дәвердә дә кайбер совет галимнәре һәм төрҗемәчеләре төрек әдәбиятына югары бәя бирүдән тартынмады. «Төрек әдәбияты,— дип язды Л. Старостов,— киң дигәндә Гомәр Сәйфетдин (1884-1920) заманыннан алып, гомум Европа мәдәнияте юлыннан тайпылмыйча үсә. Ул шуңа күрә дә бик хаклы рәвештә Шәрекъ чит ил әдәбиятлары арасында ин алга киткәне санала — аны бу жәһәттән бары япон әдәбиятына гына тиңләргә мөмкин».

Әмма шуна да карамастан, без төрек әдәбиятын бик начар беләбез. Мисалга, 1872-1979 еллар арасында кардәшләребезнең 1106 милли романы басылып чыккан, әлегә кадәр шуларның бары берсе генә татар телендә төрҗемә ителгән. Европа тәшенчесендәге беренче төрек хикәясе 1790 елда язылган һәм ул 1868 елда дөнья күргән, аннан бирле шул жанрда меңләгән әсәр ижат ителгән, әмма безгә аларның да бик азы — идеологик нәсел илоктан илоктәнгәнәре генә килеп житкә алды. Шундый ук киртәләр төрек шигърияте һәм драматургиясе юлына да корып куелган иде.

Шуңысы кызык: меңләгән роман, жомләдән, бик бай эчтәлекле һәм сөнгатьчә югары дәрәжәдәгеләре ижат ителсә дә, төрекләр үзләре бу жанрда дөнья күләм горурланырлык әсәрләре язылмады дип саный. Югыйсә, оч Кәмал — Кәмал Тәһир, Йәшәр Кәмал, Урхан Кәмал ижатларын гына да теләсә кайсы халыкның әдәбиятын биги алырлык. Ә менә хикәя язуда төрек кардәшләребез дөнья күләмендә уның казанучыларына шикләнми. Мәмдүх Шәукәт Әсәндәт (1883-1952), Сәет Фаик (1906-1954), Һалдун Танер (1915-1986), Газиз Нәсин (1915) һәм башка хикәячеләрнең Азия һәм Африкадан тыш, Америка белән Европада да таныла барулы, күрәсең, ничә тә очракны түгелдер.

Төрек әдәбияты тасырлар аша үзьин, сокларылык эшләрне һәм жирәнгеч вакыйгаларны, каһарманнарча фидакарьлекне һәм жан ошеткеч ошәкелекне тәүдәләндерсен, безне өхлакый матурлыкка ондн. Алар белән танышканда, озын тарихи юл узган, бай тормыш тәжрибәсе туплаган халыкны күзаллыйсын, шул тылсымлы көзгедә үз сүрәтен дә чагыла — могъҗизә һәм матур яшәргә этәргеч аласын.

«Заман» сезнең, хөрмәтле укучылар, төрек шигъриятенә һәм хикәясенә белән даими танышып барырга чакыра — бу саныбызда игътибарыгызга Рәшат Нури Гөнтәкин һәм Мәхмәт Акыйф Әрсуй әсәрләрен тәкъдим итә.

Рәшат Нури Гөнтәкин

күренекле төрек язучысы. Ул 1899 елда Истанбул шәһәрендә туа. 1912 елда Истанбул дәрелфөнүнен тәмамлый. Шунан соң ул Бурса шәһәренең Солтания, Истанбулның Бишекташ иттихад һәм төрекъчы мәктәпләрендә француз һәм төрек телләре укыта, аннары төрле мәктәпләрнең мөдире вазифаларын башкара. Мегариф чөлтәрендә бик озак сабак биргәннән соң, шул министрлыкның инспекторы була, Чанаккаледән Боек Милли Мәжлеска депутат итеп сайлана. Парижда Төркиянең мәдәни атташесе, ЮНЕСКО башкарма комитетындагы вәкиле булып эшли, бер ара Истанбул шәһәр театрларын идәби бүлеге өгъзасы вазифасын да үти. 1956 елда үпкәсен дәваларга баргач, Лондонда вафат була.

Рәшит Нури Гөнтәкин 21 роман, күп кенә хикәяләр, 23 сәхнә әсәре, ике том истәлек, телгә багышланган 3 һәм 16 төрҗемә әсәре бастырып чыгара.

Татар телене аның «Чалыкошы» романы төрҗемә ителә һәм ике мәртәбә аерым китап хәлендә басылып чыга.

(Хикәясе 2 биттә)

Мәхмәт Акыйф Әрсуй — күренекле төрек шагыйре, 1873 елның декабрендә Истанбулда туа. Солтан Фатих мәдрәсәсе югалгыме булган атасы Мәхмәт Тәһирдән гарәп, фарсы телләрен өйрәнә, соңыннан французчаны да үзләштерә. Яшьли шигърият дөньясына тартмыла. Беренче үзен чыккан әсәре — Фәүзиянең «Гойлә белән Мәхмүт» бүлеме үз сорнак үк яратып искә ала. Шушы еларда беренче шигырьләрен дә яза башлый. Мәхмәт Акыйф атасы хакында: «Ул минем өчен һәм ата, һәм мөгаллим иде. Мин һәр нәрсәгә ачарлан өйрәндем», — дип язып калдыра.

*Лицейны бетергәннән соң, Мәхмәт Халкалы ветеринария мәктәбенә укырга кера. Шул ук елларда спортка да бәйләнә — милли көрәш белән мавыга. Ерак һөкемдарга, вәкаләт

ЯҢАЛЫКЛАР

ТАТАР МУЛЬТФИЛЬМНӘРЕ

КАЗАНЬ. Озаклмый Татарстанның үз мультфильмнәре булачак. Казан сәнгать училищесында рассам-мультипликаторлар бүлеге ачылды. Тәләчеләр күп булса да, әлегә 10 укучы кабул ителде. Уку вакыты дүрт ел. Монда аларга компьютерлар урнаштырылган остаханәдә дә шөгыльләнергә туры килачак. Белем бирүчеләр, кинәттән буенча, Мәскәүдән мультфильмнәр җитештерүнең чын осталары чакырту да күздә тотыла. Инанасың, юлларыбыз үзебезнең осталар исәбенә мультфильмнәрне дә күрер.

РӘСТӘМ ҖЫРЛЫЙ

МИНЗӘЛӘ. Район хакимияте чакыруы буенча Рәстәм Маликов гаилә белән туган якларына концерт программасы белән кайтты. Алар районда булып узган комбайнчылар слетында да чыгыш ясадылар. Дусай-Кичү, Коноваловка, Кадрәк, Тулбай авылларында һәм Рәстәм үзе туып үскән Бикбауда да булырга өлгерделәр. Аннары аларны Минзәлә тамашачылары алкышлады. Әнә шулай, урак өстендә Маликовлар гаилә яктыларына культура хезмәте күрсәтә.

ӘКИЯТКӘ ТИҢ КИЧ

САНКТ-ПЕТЕРБУРГ. Июлдә Лавы, Менделеев һәм Питрач районнары үзешчәнләре ел да уткәреләе торган «Ак төннәр» фестивалендә булып кайттылар. Бу сәяхәт «Юлдаш» татар яшьләре клубы һәм аның рәисе Илгиз Бикчәнтәев әрдәме белән оешты. Нива буендагы шәһәрдә бу конценртлан алган тәэсирләр тамашачылар хәтерендә озак сакланыр. Ике сәгать барган тамашаны тын да алмыйча тыңлау, әсоңын — алкышлар, алкышлар!

СЕБЕРДӘ БӘЙРӘМ

ТӨМӘН. Вагай районы, Карагай авылында Себер татарларының чираттагы III район фольклор фестивале үздырылды. Фестиваль флагы күтәрелгәч, «Туган тел» җыры яңгырады. Шуннан соң төрле ярышлар башланды. Үзешчәннәр бәйгесендә Тугыз авылы сәхнә осталарына тиңнәр табылмады, алар лауреат исеменә лаек булды. Фестиваль «Татар-бермәшегез!» җыры белән тәмамланды.

«Заман» кунакханәсе

ТАТАРНЫҢ РАВИЛЕ БАР!

АЛТМЫШЫНЧЫ ЕЛЛАРДА татар шигъриятенә бер төш талантлы каләм ияләре килде: Р. Гаташ, Г. Рәхим, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Р. Мингалим... Берәвендә — хисләр кайнарлыгы, икенчесендә — җөрлек, халыкчан тел тылсымы, өченчесендә — фикер хикмәте күзәтелә иде. Миңа калса, Равил Фәйзуллин шушы сыйфатларның һәммәсен үзендә туплаган, шуның өстәвенә шигъриятне яңарту омтылышына, көрәшче гайрәтенә дә ия бер таныш иҗатчы иде.

Милли шигырь техникасын, шәкелен төрләндерү, бакый эченә алыну тумыштан шагыйрьлек орлыгы салынган кешедә генә үсә торгандыр. Чөнки ул тәжрибәнең берсе дә көткән нәтиҗәне бирмәскә мөмкин. Каләмдәшләре сыналган әзер юлдан атлап алкышлар казанганда Равил Фәйзуллин, әдәбият аксакалларын шелтәсенә карамый, үз сукмагын эзләде. Елдан елга, аның бу эзләнүләре туган әдәбиятыбыз сулышын киңәйтү, аны заманчалашгыру тырышлыгы икәнлегән, шагыйрьнең бу өлкәдә дә матур табышларга ирешүен ачыклады.

Тоталитар режим язучыга лакей вазифасын йөклән, һәр капризын абына-сөртенә канәгатьләндерүчеләргә генә яхты йөз биргәндә, татарның байтак шәһәрәтле каләм ияләре шуларга яраклашып яшәде. Бу дәвердә халыкка, хокуклары тапталган, иреге буылган милләткә, бигрәк тә хакыйкать сүзен әйтә белә, әйтә ала торган корәнчеләр кирәк иде. Хәзер кыюлар, батырлар күп, алтмышынчы-җитмешенче елларда исә әдәбият мәйданында мин шундый Салих Баттал, Равил Фәйзуллин һәм тагын бик азлар гына булганлыгын беләм.

Равил Фәйзуллин иҗатында төрле-төрле зәвеклә укучыларның һәммәсе үзенә азык таба ала. Анда традицион образлар да, шәрекъ рухы да, гарен сулышы да бар. Шуңа күрә Равил әсәрләрен татар шигъриятенә үрнәге итеп теләсә кайсы милләт вәкиленә төкъдим итәргә, шул әсәрләр аркылы аларга фәкыйлә үсен юлы узган халкыбыз рухын танытырга мөмкин. Мин моңа Эстониягә барган та ышандым. Төрки телләрдән тәрҗемәче, үзе дә әйбәт шагыйрь буларак танылган Лий Сепмель миңа:

— Равил Фәйзигезгә белэм, бик кызыклы әсәрләр яза, — дигән иде.

Равил татар шигъриятенә яшьли килеп, сәләтен елдан-ел үстереп, чынбарлыкны яңа яклары, сыйфатлары аша ачып, хис һәм фикер офыгыбызны киңәйтүгә, иманыбызны ныгытуга юмарт олеш кертте, без бүген яратып һәм горурланып әйтә алабыз: татарның Равиле бар!

Т. Әйдә

УЛ КӨННӘРНЕ ИНДЕ ДАУЛАП БУЛМЫЙ...

Ул көннәрне инде даулап булмый...
Сагынып кына була!
...Сәю ни икәнен белми гомерең узса,—
каплан да бер ела.

Сүгән еллар исәбенчә, тезеп,
кара һәмәр кабыз.
Кешеләрне күр! Хет тынлыкта кал,—
син барыбер ялгыз...

Ул елларны инде даулап булмый...
Сагынып кына була!
Үткән бәхеткә кайтып булмый,—
табынып кына була...

* * *

Гомбәзләре — коймышны!
Сары алтын — чиркәү.
Бабайларның күз яшьләре
менә кайда икән!
Төссез түгел күз яшьләре,
сары тостә икән!
Ничек ялтырый төрелер!
Акыл — көчтә икән...
Безнең якта — борынгыдан
хәрабәләр генә.
Чын тарихны азлар белә,—
хәбердарлар гына...
Гавамга мирас — моң, сагыш,—
менә калган байлык.
Шулай да әле халыкта гамь,
байтак Тукайлык.

Шагыйргә 50 яшь

ТУГАН ХАЛКЫМ

Бу дөньяда һәркем лаек ихтирамга,
расный алса яшәвенең олымын.
Туган халкым! Тарихларың давылында
югалмыйча кала алуың — горурлыгым!

Магурлыкка, гаделлеккә, тынычлыкка
хезмәт итсең — намусың пакь, нәзакәтың чын
Туган халкым! Сынауларда сабыр булып,
Җиңүләрдә ныгаюың — таянычым!

Йолдызларга менгән кеше ялгышып та
тапган китмәс шушы Җирнең бер чокырын.
Туган халкым! Илен-телен саклый алган
игелекле балаларың — киләчәгең!

ҖЫЕРЧЫКЛАР, БУ АК ЧӘЧЛӘР...

Мәңгәйдагы җыерчыклар?

Дәрьяларны айкап йөзгән чакта
дулкыннардан калган өз алар!

Бу ак чәчләр?

Тупыл мамык очырган чакта
яланбаш озак торган идем бер...
Кагынырга онытканмын!

СОРАДЫ МИННӘН ТӨШТӘ ТОТКЫН КОШ...

Бармы бер коч — канатларым очын
читлек кисәр хәнҗәр итәрлек?

Исәнме әле Күкнең зәңгәрлеге
бөтен күзләргә дә җитәрлек?

Калдымы әле җиһан иркенлеге
бар канатлар җәелә китәрлек?

... Ачыйм дигәндә читлекнең биген,
уяндым да, ачылды тик керфегем...

* * *

Бәхетләләр — ачык, кин күңелле,
риясыз, саксыз, ваемсыз.
Ә бәхетсез күп чак көчле көнче
һәм юкка да үче аяусыз...

Бәхетләләр оныта, кичерәләр,
хәсетлелек нигә алдага?
Барсын күреп торган, һәр чак аек
бәхетсездән саклан дөньяда!

* * *

Аерылганны аю ашар,
бүленгәнне — бүредер.
Аю-бүре «сәләп» читтә
күпме җанлар йөридер!

Равил Фәйзуллин шигъриләре

КӨЗГЕ ЯҢГЫР

Торналар китеп бара.
Кош канатлары орынгач,
болытларның күңеле
тулды.

ДӨНЬЯ!

Пәһләван кабере өстендә
яфраклары калтыраулы
көкре, зәгыйфь усак үскән.

СӘБӘП

Аерылышалар,
Аяк бармагындагы
Миңе ошамаган.

УЛЫМ

Ята сабый изрәп менәрәндә.
Зөнгәр күзле бөркет каурые!
Ничек итеп язар үз гомерен?..

Рәшат НУРИ ГӨНТӘКИН

ГЫЙШЫК ХАТЛАРЫ

хикәя

РӘСИМ кичләрнең берсендә, мәктәптән кайткач, үз исеменә килгән бер конвертка тап булды. Аның эчендә чәчәкле когазьгә латин хәрефләре белән түбәндәге юллар язылган хат бар иде:

«Рәсим бәй!

Мин күптәннән бирле сезгә гашыйк булган бер яшь кызмын. Матур булуымны курыкмыйча белдерә алам. Дөньяда ин татлы хыялым — сезгә ошау һәм кияүгә чыгу. Фәкать бик яшь булганлыктан, безгә берничә ел көтәргә туры килер... Шуңа күрә мин әлегә үземне сезгә танытмаячакмын. Хатларыгызны «сорап алучы Б.гә» дип... почта булегенә жибәрегез. Әгәмен иске карашлы бер кеше булганлыктан, мине урамга бик сирәк чыгара. Шулай да мин беркемне сезнең белән очрашачагыма ышанам. Үземне хәзердән үк сезнең сөйгәнегез итеп санаганлыктан, бу эштә ничбер әдәпсезлек күрмим. Әйдә ялгызлыктан әкрафаланып яшим, шуңа күрә жибәргән хатларыгызны миңа тансык бер юаныч биреп ирде.

Бәдия».

Уналты яшенә чыккан һәр мәктән баласы кебек, Рәсим өчен дә сәю-сөелүдән эһәмияткә бирнәрсә юк иде. Бу хатны укып бетерергә бетермәс йөрәгенә очкын төшмәсенме! Таныш түгел бу кызны яшүсмер егет шул минуттан ук тилерен сөя башлады: кичен 'кинога барырга ниятлөген иде — ваз кичте. Бүлмәсенә кереп бикләнде дә үзен сөйгән бу кызга озын бер хат язды. Аны почта тартмасына илтен салгач, ун яшькә олы гайгандай, күкрәгенә татлы горурлык тойгылары кереп тулды.

Исемен Бәдия дип таныткан бу яшь кыз егетенә бик тиз жавап бирде, өгәр Рәсимнең хаты бер-ике көн кичми торса, кыямәт куптарырга гадәтләнеп киттө.

«Сезнс ничек сәюсн һәм өйдә ялгызы бикләнеп ятәсен, сезнең хатларыгыздан тыш бер юаныч да булмаган хәбәр иткән кызны шулай кәттәрен тилмертү ярыйммыни? Житмәсә, хатларыгызны да үтә кыска язасыз: әллә минем белән аңлашудан кыенсынасызмы? Әнә бер үтенечем бар: хатларыгызны аңсатрак танырлык итеп языгыз әле!»

Яшүсмер егет кичләрен бүлмәсенә бикләнеп, сөекле сенә ошарга тырышып, сөгатьләр буе сүзлекләр актарырга, караламалардан кат-кат күчереп озынозын хатлар язарга тотынды.

Бәдия күп нәрсә белән кызыксынучан кыз булып чыкты. Бервакыт егетенә менә шундый сорауллар да тезеп жибәрген иде:

«Ойләнешкәч, баллы аебызны уздыру өчен кая барсак, яхшы булыр икән — Италиягәме, Швейцариягәме? Бу ике ил нинди рәк — халкы ничек яши, нәрсә майтара? Аларга барып житәр өчен кайсы дингезләрдән, кайсы мәмләкәтләрдән кичерләр?»

«Син Габделхак Хәмит бөйнең «Эшбер»ен укыдыңмы? Аның кайсы жирләрен ошатмыш?»— дигән иде ул бер хатында. Рәсим, гашыйк кыз алдында дәрәжәсен төшермәс өчен, география дәреслекләрен, әдәби китапларны кат-кат укырга мәжбүр булды, сорал-ган мәгълүматларны туплар өчен көнне төнгә ялган, шуларга күз нурын түкте.

Бер хатында Бәдия аңа үпкәсен дә белдергән иде.

«Мин сезнең белән күрешергә карар бирген идем. Мәктәптән кайту юлыгызда көтеп тә тордым. Ләкин сез бер яшь кызның сейгән яры булуыгызны оныткансыз икән: өс-башыгыз карарлык түгел, ботинкагыз пычракка

(Ахыры 4 нче битта).

(Ахыры. Башы газетабызның 4, 5, 6 саннарында)

«Истанбул мәктүпләре»ндәге бер мәкалә лирик парча формасында языган. Ул — «Мәрмәрә буенда «Зиләйлүк» дип атала. Моны, ихтимал, әдәби әсәр булганлыгы очендер, «Шура» журналы да «Вакыт»-тан алып баскан (1913, № 9). Әсәр Ф. Кәриминең патриотик хисләренә корылган. Төрекләргә «дин, кан кардәшләремез» дип барган язучы да, бу илдәге феодаль тәртипләр, наданлык, хәерчелекне күрен танышканнан соң, бервакыт үз Ватаны — Русиягә кайтып ихтирам хисләре кайнар ташып чыга, ул Ватанын сагына башлый. «Истәлале Әхмәрә» исемендә килгән бер татар егете белән Босфор буена чыгалар да. «Зиләйлүк», «Тәфтилөү» кеек жырлыйлар. Күңелләр тазиз Ватанга мәхәббәт, сагыну хисләре белән ташый.. Бу жыр белән алар Ватанга сагыну сәламе жибәрәләр. Ләкин чынбарлык аларның бу күтәренке хисләрен жимереп ташлый: «Әрабәләр арасыннан сәләмә киемле, ачлыкланган чыккан жәфа чиккән ике хатын килеп чыга. Ирләре сугышта, балалары авырдан үлгән. Йорт-жир, ашау-эчү өйберләре юк. Алар жырчыларга: безнс моннан Русиягә алып китегез, без хәерчелектән алжыдык, дип ялвара. Әле генә бөек изге хисләр, күтәренке күңел иде. Боларның жырларын Мәрмәрә диңгезенең дулкынлары тынлый кебек һәм Ватанга алып китәр кебек иде... Жырчылар фаҗыйрьлек, сугышның мондый корбаннарын күреп сүзсез кала. «Зилэйлүк»ләр оныта. «Тормышның иң дәһшәтле во колак ерткыч нәгъмәләре (көй) килеп колакка бәрелдә... Моға мә фиһ (шуның белән бергә), «Зилэйлүк» илә «Тәфтилөү» көйлеребезнең Мәрмәрә дулкынларына кушылып обәдияткә (мәнгелеккә) таба китүләре дә шөбһәсез иде». Шыксыз чынбарлыкның драмасы шулай ирен журналист каләмен лирик рухта хикәяләүгә таба алып керен китә.

Соңгы мәкаләләрендә Ф. Кәрими Төркия халкына бу карангылыктан чыгу өчен юллар эзли. Культура юлы карангылыктан чыгуның бердәнбер чысулы дип ышанган мәгърифәтче хәзер инде котылуның социаль, дипломатик юлларын тырында уйлана һәм «авыру Төркыя» шактый төгәл диагноз куя: Төркиянең үз кулында банклары юк. «Хәзерге вакытта банкларның хакимияте хөкүмәтләрнең хакимиятеннән артыграктыр». Бу инде Ф. Кәрими стихияле рәвештә империализмның төп сыйфатларын аңлауга якын килгән дип әйтергә нигез бирә. Төркиянең, диүл, «бер яктан иске гаһәдномәләр (килешүләр) илә, икенче яктан икътисад, тижарәт (сәүдә) вә сәнәгать (промышленность) жәһәтләреннән булган төшенкелек илә... аяклары, куллары багланган... Үл үзе төләгәнчә эш йөртә алмый, йөртергә ирек бирмилэр». Болардан котылу юлы Ф. Кәримичә болай: төрекләрнең мәхәббәтен Русиягә жәлеп итү, Русия белән Төркия арасында сәүдә мөнәсәбәтләрен арттыру һ. б. Бу бурычлар, ди автор, «Русия мәнфәгатенә иң муафыйк бер нәрсә». Бу Ф. Кәриминең гуманистик фикер йөртүе, изелгән халыкларга ярдәм итү ысулларын эзләвө иде.

Ф. Кәрими, намуслы язучы-журналист буларак, үзе мәхәббәт белән караган Төркия турында язганда сәяси хисләрен жиңеп, хакыйкатькә омтыла. Төркиянең «хәлифәлек», «госманлылык» шәһрәтен мәкаләләрендә тетеп ташлый. Кая ул Төркиягә дөнья мөселманнарына баш булырга! Аның өле өүвәл милләт буларак үзен-үзе таныйсы, үзендә Ватан дигән олы бер хис тәрбиялисе бар икән! «Истанбул мәктүпләре»ндә мөселманчылык торгынлыгы зур ышандыру көче белән фаш ителә. «Мөселманчылык», мәгълүм ки, колониаль державалар изүе астында жәфа чиккән Көнчыгыш халыкларын язмышларына риза булырга, риминнең ахырдан «Истанбул мәктүпләре» дигән исемле китап булып чыккан кызыклы корреспонденцияләре басылды. Автор үз күзе белән күргәннәрне ихлас күңелдән язып барган, кайвакытта аның калә-мәннән аянычлы авазлар ишетелгәләде, чөнки Төркиядән гайрәте чигу ана бик авыр булды. Бу «мәктүпләр» «Яшь төрекләр» белән күзләре сукырайган мөселманнарның да күзен ачты. Төркиядә булып кайткан мөселман интеллигенты шулай итеп Төркиянең тарткалачагы котылгысыз икәнлегенә ышанып кайтты» (В. Гордлевский. «Война и русские мусульмане». Газ. «Русские ведомости», 1914, и 266).

Балкан сугышы, Төркия язмышы мәсьәләләрен Ф. Кәрими аннан соң да публицистикасында кат-кат күтәрә. Русия мөселманнарының белем, мәгърифәт ягыннан Төркия мөселманнарына караганда югары торганын Ф. Кәрими мәкаләләрендә алга таба да күрсәтә. Ул Русия белән аралашуның, урыс әдәбиятының татар мәдәни үсешендә унай йогынтысын зур горурлык белән әйтә. Гомерe буе Русия-Төркия мөнәсәбәтләрен яхшыртырга каләме белән көрәш алып барган журналист әле 1914 елда да, Төркия хөкүмәте Русиягә һөҗүм итү өчен сәрби көймәләрен әзерли башлаган чорда да, мәгърифәтчеләрчә беркатлылык белән шундый фикерне пропагандалый: безнең илдә урысча белем алган мәгърифәтле мөселманнарны Төркиягә күрсәтү бик әһәмиятле, бу һәрсә ике дәүләт арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләрне яхшыртыр иде, дип яза («Вакыт», 1924, № 1475).

Ф. Кәрими яза торган нәрсәсен бик жентекләп өйрәнә, темасын тирән белә иде. Ул

(Ахыры 4 биттә)

ФАТИХ КӘРИМИНЕҢ «ИСТАНБУЛ МӘКТҮПЛӘРЕ»

Мөхәммәт Мәһдиев

ZAMAN
FARKLI GAZETE
TATARİSTAN

Cumhurbaskanı İzzetbegoviç ZAMAN' a açıkladı: Süren vahşet karşısında dünyanın tavrı utanç verici

'Bosna, tarihini kanla yazıyor'

ZORAKİ TEBESSÜM: Bosna İle birlikte İzzetbegoviç de çöktü. Yüzbinlerce ölü ve milyonlarca mültecinin tezirabını yaşayan Müslüman lider objektiflere poz verirken güçlükle gülümsüyor

MEHMET KOCA

CENEVRE- Bosna zirvesinin yapıldığı Cenevre'de gazetemiz ZAMAN'a bir açıklama yapan Bosna Hersek Cumhurbaskanı Ali İzzetbegoviç, **"En karanlık günlerini yaşayan halkımız, tarihini kanla yazıyor. Her gecenin bir sabahı olduğu gibi her kötü günün de mutlaka ak günleri vardır. Biz milletçe bu karanlıkların ardından doğacak şafağı bekliyoruz. İnanıyoruz ki bu şafafın doğum sancılarını çekiyoruz. İnşaallah zafer yakındır"** dedi.

Yorgun olduğu yüzünden belli olan Cumhurbaskanı İzzetbegoviç ile President Oteli'nin lobisinde konuştuk. Bizi Türkçe olarak selamlayan İzzetbegoviç, bizim deyimimizle tam bir ihtiyar delikanlı. 68 yaşındaki bu lider milletinin sorumluluğunun bilincinde, tüm baskılara karşı halkı için direnen iman ve inanç örneği bir mücahit. Bosnalılar ona Bosna Fatihi diyorlar, gerçekten çok haklılar. Alçak gönüllü ve çok nazik bir insan. Zor günlerin adamını, tam on genç koruyor ve etrafında kuş uçurtmuyorlar. Gecenin 23.30'u olmasına rağmen bizleri kabul eden Cumhurbaskanı resmen baskı altında olduğunu belirterek, ülkesi Bosna Hersek'in bölünmesine müsaade etmeyeceğini söylüyor.

Birleşmiş Milletler ve Avrupa Topluluğu'nun yanlı ve yanlış politikalarıyla akan kanın ve dağılan yuvaların bir yerde sorumlusu olduğunu söyleyen İzzetbegoviç, durumun utanç verici olduğunu söyleyerek, "Bizlerin ülkemizi bölmek ve bizi yok etmeye yönelen taraflarla işbirliğinde olan güçlerin hazırladıkları planları kabullenmemiz mümkün değildir. Ülkemiz etnik ayrılığa dayalı bir bölünmeye müsait değildir. Savunma hakkımız uygulanan ambargoyla verilmediği için çok zor şartlar içinde olduğumuzdan dolayı ülkemizin bütünlüğü esas alınarak ülke içinde etnik ayrılık düşünülmeden eyaletlerden oluşan bir federasyonu makul ölçüler içinde kabul ederebiliriz.

Ülkemizde, Sırp ve Hırvat saldırıları durdurulmadan ve acil ihtiyaç malzemeleri taşıyan yardım konvoylarına müsaade edilmeden yapılacak tüm andlaşmalar şimdiye kadar olduğu gibi bundan sonra da kağıt üzerinde kalacağı gibi girişimlerin de bir anlamının olmadığı ortaya çıkacaktır, Şimdiye kadar ki tüm andlaşmaları ihlal eden Sırp ve Hırvatlar'ı Birleşmiş Milletler cezalandırmak yerine, bizi kabul edilemez andlaşmaları kabule zorlamaktadırlar" dedi.

Bosna Hersek konusunda İslam ülkelerinin gösterdiği ilgi ve yardımın yeterli olup olmadığı şeklindeki sorumuzu da cevaplandıran Cumhurbaskanı Alia İzzetbegoviç şunları söyledi: "Biz en olumsuz şartlara rağmen inanç ve benliğimizi korumak uğruna saldırgan güçlere direnerek, hem Allah'a hem milletimize karşı vazifemizi yerine getirmeye çalışıyoruz. Eğer İslam ülkeleri bizi anlar ve bize sahip çıkarlarsa üzerlerine düşen vazifeyi yerine getirmiş olurlar. Unutulmasın ki çok zor günler yaşıyoruz. Ülkemiz alevler içinde bağlar bahçeler mezar oldu. Her zamankinden çok yardıma ihtiyacımız var.

Başta ülkeniz Türkiye hükümeti ve büyük sevgi beslediğim, saygı duyduğumuz halkınızın yardımlarına müteşekkirim ancak daha çok desteğe ihtiyacımız var ve yardım bekliyoruz. Zira İslam aleminin bizi ölüme terkedeceğine inanmıyoruz."

DOĞACAK ŞAFAĞI BEKLİYORUZ

"Aralıksız saldırılar ve baskılar altında var olma mücadelesi veriyoruz. En karanlık günlerini yaşayan halkımız tarihini kanla yazıyor. Her gecenin bir sabahı olduğu gibi, her kötü günün de mutlaka ak günleri vardır. Biz milletçe bu karanlıkların ardından doğacak şafağı bekliyoruz. İnşallah zafer yakındır"

ÜLKEMİZ ALEVLER İÇİNDE

"Allah'a ve milletimize karşı vazifemizi yerine getirmeye çalışıyoruz. İslâm ülkeleri bizi anlar ve sahip çıkarlarsa üzerlerine düşen vazifeleri yerine getirmiş olurlar. Çok zor günler yaşıyoruz. Ülkemiz alevler içinde. Bağlar bahçeler mezar oldu. Daha çok desteğe ihtiyacımız var. İslam aleminin bizleri ölüme terk etmeyeceğine inanıyoruz"

AT VE BM SORUMLU

"Birleşmiş Milletler ve Avrupa Topluluğu bir yerde yanlı ve yanlış politikalarıyla akan kanın ve dağılan yuvaların sorumlusudur. Bu durum üzücü olduğu kadar utanç verici. Bizlerin ülkemizi bölmek ve bizi yok etmeye yönelen taraflarla işbirliğinde olan güçlerin hazırladıkları planları kabullenmemiz mümkün değildir"

TESBİT

MEHMET KARABACAK

Bosnayı bölenler, Kıbrıs'ı birleştirmeye çalışıyor

Bosna'da Sırplar'ın rüyası gerçekleşiyor. Bosna, "etnik" ulus anlayışına dayalı üç ayrı devlete bölünüyor. Bundan böyle Sırplar, Hırvatlar ve Boşnaklar Bosna'da birarada değil, kendi devletlerinin sınırları içinde yaşayacaklar. Bunun geçici bir çözüm olduğu, Boşnaklara bırakılan toprakların ilk fırsatta Sırplar ve Hırvatlar arasında bölüneceği ve Sırbistan ile Hırvatistan'a katılacağı kanaatleri ise uzmanlar arasında oldukça yaygın.

Bosna'yı kim bölüyor? Görünüşe bakılırsa silah zoruyla Sırplar... Ama aslında Bosna'yı bölen, Birleşik Amerika'sından tutun İngiltere'sinden Almanya'sına Fransa'sına ve ambargonun sürmesi için Güvenlik Konseyi'nde veto kullananlarına kadar, Batı'dır...

O Batı ki, başlangıçta, **"Bosna'da etnik temizlik istemiyoruz." Güç kullanımı yoluyla toprak kazanılmasına karşıyız, bunu kabul edemeyiz"** diye bas bas bağırıyordu. Ama sonunda, Sırpların zorbalığı karşısında hiçbir şey yapamadığı için, "etnik" ayrılığa dayalı bir bölünmeyi, Bosna'daki çatışmayı önleyecek tek yol olarak görmüş ve benimsemiştir.

Bosna'da Boşnaklara böyle bir çözümü zorlayan yalnız Sırp silahları değil. Batı'nın arabuluculardır. Şimdi **"Başka yol yok"** diyenler, onlardır.

Sırplar yapınca ve de onlar onaylayınca bu tür bir çözüm, ne ülkelerin bölünmez bütünlüğü ilkesine, ne de silah yoluyla toprak kazanılmayacağı ilkesine aykırı oluyor. Herşey kitaba uygundur.

İşin acı yanına bakınız ki, Bosna'da Sırp zorbalığı karşısında sessiz kalıp sonunda etnik ayrılığı ve Bosna'nın üç devlete ayrılmasını çözüm olarak benimseyenler, Kıbrıs'ta Rum zorbalığından kaçarak kendi devletlerini kurmuş olan Türklere, yıllardır, **"Rumlarla yeniden birleş"** diye baskı yapıyorlar. Washington'da State Department'in, New York'ta BM'nin kulislerinde, Rumlarla Türkleri yeniden içiçe sokacak planlar hazırlayıp duruyorlar. Olacak şey midir?

Kıbrıs'ta Türklere, **"Seni elindeki topraklar Türklerle Rumlar'ın nüfus oranına göre çok fazla, bir kesimini geri vereceksin"** diye ayak diretiliyor. Oysa Bosna'da Müslüman Boşnaklar'ın toprakları, nüfus oranına filan bakılmaksızın Sırplar'a ve Hırvatlara peşkeş çekilmektedir.

Daha da acısı, bu yeni dünya gerçekleri ortadayken kimse, kalkıp da Batı'ya, "Sen ne oluyorsun arkadaş? Bosna'yı kendi elinle bölerken, nasıl olup da Kıbrıs'ı yeniden birleştirmek isteyebiliyorsun?" demiyor.

Bosna'yı bölenlerin, Kıbrıs'ın birleşmesini istemeye hakkı yoktur. Bu dünyayı katliamlar haritasına döndüren batılılara artık açıkça söylenmelidir.

Batı artık dünyanın dinamosu değil

ABD, Japonya ve Avrupa durgunluktan çıkmak için savaşırken, Latin Amerika ve Uzakdoğu Asya en canlı yıllarını yaşıyor

Batı dünyasında ekonomi hasta yatağından kalkmaya çalışırken, Uzakdoğu Asya ve Latin Amerika'daki bazı ülkeler atağa kalktılar.

Fortune Dergisi'nde dünya ekonomisiyle ilgili bir yazı yayınlandı. Yazıda dünyanın bazı önemli bölgeleri açısından genel durum incelenliyor. Gezegenin rakamlarla en iyi durumdaki 20 ülkesi hâlâ ABD, Kanada, Avustralya, Hong Kong, Japonya ve Batı Avrupa ülkelerinden oluşuyor. Çünkü, gelişmekte olan ülkeler ne yaparlarsa yapsınlar, ne GSMH'de, ne kişi başına düşen milli gelirde bu ülkelere yetişemiyor. Birleşmiş Milletler'in oluşturduğu "İnsani Gelişme Endeksi"ne göre de sıralama hep gelişmiş ülkeleri kapsıyor: Sırasıyla Japonya, Kanada, Norveç, İsviçre, İsveç, ABD, Avustralya, Fransa, Hollanda ve İngiltere.

Ancak, yüzyılların sağladığı bu avantaj, gelişmiş Batı dünyasının, gezegenin en dinamik, en canlı ekonomik bölgesi olduğu anlamına gelmiyor. ABD resesyonden yeni yeni çıkıyor, Avrupa hâlâ sakat, Japonya'da da yoğun işten çıkarmalar'la kendini gösteren hastalık belirtileri var.

Dünyanın en canlı, en hızlı büyüyen bölgeleri artık Uzakdoğu'daki Çin, Tayland, Endonezya, Filipinler, Malezya ile Latin Amerika'daki Arjantin, Meksika, Şili gibi ülkeler.

Örneğin, ihracatta Güney Kore, Tayvan, Hon Kong ve Singapur dördü birarada ABD ve Almanya'ya yetişiyorlar.

Sabit sermaye yatırımlarındaki artış hızına bakıldığında, yine yeni sanayileşmiş ülkeler Batı'nın çok önünde. Japonya bu konuda teklemeye başlarken, Asya'nın yeni dinamoları Tayland, Malezya, Hindistan öne geçiyor.

Yabancı sermaye yatırımlarına bakıldığında Meksika, Singapur, Brezilya, Şili, Malezya gibi kimi ülkelerin bundan birkaç yıl önce adı bile geçmezken ön sıralara geçtiği, Avrupa ülkelerini geride bıraktığı görülmektedir.

Sabit Sermaye Yatırımlarındaki Artış



Doğrudan Dış Yatırımlar (1991)

Gelişmiş ülkeler	Milyar dolar	Gelişmekte olan ülkeler	Milyar dolar
İngiltere	21.1	Meksika	4.8
Fransa	15.2	Singapur	3.6
ABD	11.5	Malezya	3.5
İspanya	10.5	Tayland	2.0
Belçika	9.4	Venezuela	1.9
Almanya	6.6	Endonezya	1.5
İsveç	6.4	G.Kore	1.1
Avustralya	4.7	Brezilya	0.9
Kanada	4.5	Şili	0.6

BMW'de durgunluktan etkilendi

Alman lüks otomobil üreticisi BMW'nin net karı 1993'ün ilk altı ayında yüzde 40 azaldı. Almanya'da otomobil üretimi, resesyon sebebiyle geriyle 313 binden 217 bine düştü.

Alman lüks otomobil üreticisi BMW altı aylık sonuçlarını açıkladı. Dünya otomotiv sektöründeki kriz, BMW'yi de etkiledi. Net kâr bu altı aylık dönemde yüzde 40 azalarak 225 milyon marka düştü. Gurubun cirosu da yüzde 9 azaldı ve 14.7 milyar mark olarak gerçekleşti.

IBM 60 bin işçi daha çıkaracak

1993 yılının başından bugüne kadar 50 bin kişiyi işten çıkarmış IBM 1994 sonuna kadar dünyadaki tüm şirketlerinden 35 bin kişiyi daha işten çıkaracağını, 1994 sonunda ise çalışan sayısını 225 bine indireceğini açıkladı.

IBM'in net zararı 8 milyar dolar olarak açıklandı. Şirket zarardan kurtulmak için küçülmeyi tercih etti. İşgücünden üretime kadar her yerde almacak bu indirim tedbirleriyle, her yıl 4 milyar dolarlık bir tasarruf sağlanabileceği hesaplandı.

ABD Başkanı Bill Clinton'un baş danışmanlarından Martin Indyk

Türkiye Ortadoğu'da barışın, denge ülkesi

Ankara, Ortadoğu barış gelişmelerine ve bölgedeki siyasi oluşumlara yön verebilecek bir güce ulaştı. ABD Başkanı Bill Clinton'un baş danışmanlarından Martin Indyk, ABD'nin Türkiye' siz bir Ortadoğu'da barış sağlamakta güçlük çekeceğini, bu yüzden Türk hükümetine çok büyük bir rol verilmesi gerektiğini söyledi. Indyk, Arap-İsrail çatışmasından bölgenin su problemine ve Irak ile Kürt meselelerine kadar birçok sahada daha geniş bir etkinliğe sahip olmayı isteyen Türkiye' nin bu talebinde haklı olduğunu da vurguladı. Başdanışman Martin Indyk, Financial Times gazetesinde yer alan demecinde özetle şunları söyledi:

Körfez Savaşı'nın patlak vermesiyle Türk yetkililer uzak bir Körfez ülkesinin güvenliğine yönelik tehdidin bile Türkiye'yi çok yakından ilgilendireceğini anlamış oldular. Bu tecrübeden sonra Türk savunma bütçesinin 4 milyar doları çıkartılması da Türkiye'nin artık bölgedeki bütün gelişmelerden etkileneceğini gösteriyor.

Şu gerçek gözönünde tutulmalıdır ki, daha ikl-üç yıl öncesine kadar, hiçbir Arap bakan, Ortadoğu barış görüşmelerinde Türkiye'nin bir rol oynayacağı ihtimalini aklına bile getirmezdi. Keza, herhangi bir Türk bakan da böyle bir seve akıl enilemezdi.

Fakat şimdi Arap hükümetleri Türkiye'nin bölgede giderek artan ve hissedilir hale gelen önemini yurgulamaktan kaçınmıyorlar. Örneğin Ürdün Dışişleri Bakanı Talal el-Hasan Türkiye'nin bölgedeki ağırlığının ve etkisinin göz ardı edileniyeceğini söyleyen birçok yetkiliden sadece bir tanesi. Dışişleri Bakanı Hikmet Çetin de Türkiye'nin önemini Arap dünyasının gözünde ne kadar büyüdüğüne yakından şahit olan birkaç politikacıdan bir tanesi. Türkiye, ekonomik, askeri ve siyasi açıdan bütün İslâm ülkelerine model olabilecek ve örnek alınması gereken bir devlet olmuştur.

ТАТАРГА ТЫЛМАЧ КИРӘКМИ

ТӨРЕКЧӘ ӨЙРӘНЕБЕЗ

7 дәрес

Татар телендәге кебек үк, төрек телендә дә кеше җенесен билгеләүче махсус грамматик чаралар юк. Сөйләм һәм язма телендә бу мәсьәләнең табигый рәвештә чишелүе һәм бернинди кыенлык чыгармавы белән бергәттән, ир һәм хатын-кыз җенесләрен аеручы кайбер күрсәткечләр кулланыла. Боларны 4 төркемгә тупларга мөмкин.

1. Җенес принцибына нигезләнгән күрсәткеч, мәсәлән:

erkek — ир; **kadın** — хатын-кыз
oğlan — ул; угыл, **kız** — кыз

2. Ир яки хатын-кыз җенесенә карау туганлык атамалары ярдәмендә күрсәтелә:

baba — ата; **ana (anne)** — ана, әни
kardeş — эне; **kız kardeş** — сеңел
ağabey (abi) — абый; **abla** — апа
dayı — ана ягыннан абый кеше; **teyze** — ана ягыннан апа кеше
amca — ата ягыннан абый кеше; **hala** — ана ягыннан апа кеше

3. Кайбер хайваннрны женесләре буенча аерыр өчен аерым сүзләр-бар:

teke — кәҗә тәкәсе; **keçi** — кәҗә
koç — сарык тәкәсе; **kouyun** — сарык
horoz — әтәч; **tavuk** — тавык
öküz (boğa) — үгез; **inek** — сыер

Башка очракларның күбесендә уртак хайван исеменә — **erkek** (ата, иркәк) һәм **dişi** (ана, теше) сүзләре остәлә. Мәсәлән:

erkek kaplan — ата юлбарыс
dişi yılan — ана елан

4. Кешенең һөнәрен күрсәтү ихтыяҗы чыкканда, хатын-кызлар өчен

kadın — сүзе кулланыла. Мәсәлән:
kadın mühendis — инженер хатын
kadın boyacı — буяучы хатын-кыз

ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ ИСЕМ

ХӘБӘР (берлек саны, 3 зат)

Исем хәбәр исемгә басымсыз **—dır** кушымчасы ялгану юлы белән ясала. Сузыклар гармониясе канунына буйсынып, хәбәр кушымчасы 4 шәкелгә керо ала: **—dır,— dir,— dur,— dür.** Исемнең соңгы авазы саңгырау тартык булганда, әлеге кушымчалар башына t тартыгы китерелә: **— tır,— tir,— tur,— tür.**

Мисаллар: а) исемнең соңгы иҗегендә «а» яки «ı» сузыклары булган очракта кушымча — **dır (tır)** шәкелен ала:

bu tavandır — бу түшәм
bu darıdır — бу дары
bu dolaptır — бу шкаф
bu tanıdıktır — бу таныш (кеше)

Искәрмә: язуда һәм сөйләмдә хәбәр кушымчаларын кулланылмаска да мөмкин.

б) соңгы иҗегендә «е» һәм «i» сузыклары булган исемнәргә — **dir (tir)** кушымчасы ялгана. Мәсәлән:

bu penceredir — бу тәрәзә
bu nöbetçidir — бу кизү (дежур)
bu kelebektir — бу күбәләк
bu kilittir — бу йозак

Бәйрәмнәр, истәлекле көннәр белән бәйле рәсемнәрне, шигырьләрне, сценарийларны, сәхнәләштерелгән уеннарны, концертларны, спектакльләрне, кичәләрне, конкурсларны, викториналарны, сәяхәтләрне, экскурсияләрне, экспедицияләрне, ял көннәрендә үткәрелә торган башка чараларны, шулай ук мәктәп тормышының башка якларын яктырткан материалларны көтәбез.

Материалларны «Татарга тылмач кирәкми» дигән билге белән почта аша редакциягә җибәрегез.

Нәзиһ ҮЗӘЛ

ГЫЙБА-ДӘТХАНӘ

МОННАН НӘКЪ 436 ел элек, шулай ук июнь аенда, жир йөзендә кеше куллары белән төзелгән иң матур биналарның берсе корылып бетте. 1557 елның 7 июнендә Истанбулдагы Сөләймания мәчете үзенең күркәм капуларын халыкка гыйбадәт кылырга ачты. Госманлы падишаһы Солтан Сөләйман Кануни намына, сәләтле мигъмарлар (архитекторлар) башлыгы Синан Габдельмәннан тарафыннан торгызылган бу олы гыйбадәтханә жиде елда тәмамланган иде.

Сөләймания мәчете намуслы бер дәүләтнең, тәдәләтле бер падишаһның һәм «иң камил дин шәрәфе илә яшәгән» дерес бер халыкның «тарихның бәхетле бер чорында» мәйданга чыккан бөек бер мәдәният һәйкәлеләр. Ул кешелекнең бер энҗеседер. Таш, кирпеч, тимер, кургаш, мәрмәр, пыяла, такта, торба һәм ком-акбурдан гыйбарәт бер «рухның челтәрен агуыдыр». Хак Тәгаләгә «буйсыну вә ялварыу»дыр. Диндар бер падишаһның нәзере... Төкъва бер мөхәллөнең ижтиһады...

Дөньяның иң бөек хөкемдарларыннан «мәһабәт» кушаматы белән йад ителгән Сөләйман тарафыннан дөньяга калдырылган бу әсәрнең беренче ташы кайчан салынуы билгесез. 1550 елда коннәрнең берендә... Әмма, кайсы көнне? Билгесез. Сагый Чәләби тарафыннан төзелгән «Тезкирәт-ел-бенъян» («Бина төзү кулланмасы»)нда Синан-мигъмар моны: «Бер шанлы вакытта — рәхәт һәм күңелле сәгатьтә шул күренекле мәчетне нигез салынды»,— дип ачыклый.

Сөләймания мәчете салынганда, иң ерак илләргә кадәр императорлыкның бөтен олкәләре хәрәкәткә китерелә. Чал тарихчы илләр бергә очраша, госманлы мәдәнияте дөньяга бер хатирә калдыру ижтиһадына керешә.

Тимер — Болгарстандагы Самаховдан; кургаш — Төньяк Сербия һәм Боснададан; кирпеч — Галлиполидән; агач — Карадингез тауларыннан килә. Мисыр һәм Ливаннан китереләчәк таш батаналар өчен махсус көймәлар төзелә. «Карынчы» («Кырмыска») исемле бер көймәнең капитаны Сөләйманның өчен Истанбулга китергәнен бер таш багананы падишаһка шушы шигырь белән сона:

Карынчылар бодын чикергодын Сөләймана
Сезә ялекъ нәмез варса, кабул айлә факыйрана.
(Кырмыскалар бөтен сүзгән чикәртәкләй Сөләйманга Сезгә лаек нәрсәбез булса, кабул ит факыйреннан).

Сөләймания мәчетенең төзелешенә мөнәсәбәте белән Әрегълидә эшләтелгән бер таш учагында (шахтасында) кулланылган көйләһем көрәкләр, төннәрен дәүләт тарафыннан арендаланган бер йортта тотыла. Йорт хакы бер айга сонарга, Әрегъли кызые Истанбулга: «Ятим хаккыдыр, падишаһымыза жавап жәзасы улмасын,»— дигән бер хат күндерә. Акча шундук түләнә.

Сөләймания мәчетенең вәкъфиясенә (вәкыф салган малның документы) караганда, аның 275 хезмәтчесе булса. Алар императорлык дәверендә һәммәсе шул эшендә сакланылганнардыр, дип уйлыйм. Бүген мәчеттә икс имам, биш мөэзин, бер назир (опекун) һәм бер бакчачы — барысы түгыз кеше бар.

Сөләймания. Олы гыйбадәтханә. Дөнья исөн-имин чакта шуның иҫе тагын бөрәр бина төзелерме? Ул бөек кешеләр һәм ул «мәһабәт» дәверләр яңә килсә, бәлки. Өметсез шәйтан бит...

Сәрхүш очучылар

Франкфурт (Анадулы агентлыгы).

Чит ил һава юлларында эшләүче бер төркем очучыларның очыш вакытында хәмер, хәтта наркотиклар куллануы, кайсыларының исә йөкьгага каршы дару файдалануы билгеле булды.

«Бильд ам Зонттаг» гәзите, әлеге күренешкә һава юлы ширкәтләре аңлы рәвештә күз йома, дип яза. Гәзит, үз сәхифәләренә, мәсьәләгә турыдан-туры кагылышлы тикшерениүләр алып барган дөссельдорфлы бер медицина профессорының язмасына урын бирә. Тикшерену төрле һава юлы ширкәтләре арасында үткәрелгән, барлыгы 318 очучыны колачлады.

Профессор Әмир Арбабзадә очучылардан кан һәм бавел анализлары алып, шуларның 28 процентында уяу булуны тәэмин итүче дару, кокаин һәм шуның ише наркотиклар барлыгын ачыклаган. Профессор сүзенчә, очышка әзерләнеп торган бер пилот канында күп микъдарда хәмер табылган.

«Бильд ам Зонттаг» шулай ук, Лондон аэропортына төшеп утырган американ очучы Джон Д.нын: «Шулкадәр исерек идем, очкычны ничек итеп утыртканымны да белмим», рухындагы сүзләрен бастырган. Әлеге пилот һавада чакта аракысын кырыну лосьонына катнаштырып әкрелән йоткын барган икән.

Хәлбуки, канун буенча пилотларга аракы эчкәннән соң иң кимә 12 сәгать очкыч белән идарә итү тыела, наркотиклары исә очучылар, гомумән, кулланырга тиеш түгел.

Иншалла, бездә мондый пилотлар юк әле.

49 яшендәге Атилла Беганг быелга кадәр үрнәк бер хезмәткәр санала килде. Ул хөкүмәтнең чит ил мәкаләләры дәирәсе бүлек башлыгы вазифасын жиренә житкәрп башкаруына ышанып яши иде. Әмма лөкин 11 майда, кызу бәхәсләрдән соң, Мажарстан (Венгрия) парламенты Украина белән сугыштан соңгы чиклөрнең үзгәрмәслеген кабул итә, ике якны килешүне раслагач, Атилла өчен дөньяның асты өскә килде. Аның фикеренчә, бу карар Украинадагы 200 мең мажарны язмышн иркенә ташлау белән бер идә. Атилланың түзәрлеге калмады. Хезер инде ул үз министрын ачу белән төнкылтьлы, берьюлы Тышкы эшләр министрын һәм премьер-министр Йожеф Анталлны да өлешсез калдырмый, хәтта аларны хөкемгә тарттыру белән дә яный башлады. Инде бу төнкылтьнең нәтиҗәсе нинчегрәк булды соң? Атилла Бегангны эшеннән азат иттелөр!

Шуңа карамастан, Атилла көрәшеннән һич тә ваз кичмәячәге турында белдерә.

Бегангның чаң кагуы бик күп мажарның өлө дө төзелмөгән тарихи ярасын сызлата. Ул яра — 1920 елда имзаланган Триданон килешүе... Сугыштан жиңелеп чыккан Мажарстан бу килешүгә кул кую нәтиҗәсендә, жирнең өчтән икс һәм халыкның өчтән бер өлешен югалткан иде. Алар курше илләргә — Румыния, Чехословакия һәм Югославиягә бирелде.

Ул заманнарда Мажарстан мөктәпләрендә укучылар һәр иртәдө болай жырлый торган булган:

«Кечкенә Мажарстан бөек ил түгел, чын ватанныбыз — бөек, зур Мажарстан!»

Инде хезер әлеге бөеклек, мәһабөтлек мажарлар күңелендә хәтирә булып кына сакланып калса да, аның шөүләсе һаман күз алдында. Тарихларын оныткаган ватандашлар Триданон килешүенә 73 ел тулган 4 июнь көнне Будапештта демонстрация оештырып, аңа тагын каршы чыкты. Ауруна илләренә таралып яшәгән мажар азчылыгы мәсьәләсе сәясәтнең көн тәртибенә житкән бер төстә килеп басты. Мажарстанга чиктән мәмләкәтләрдә 3 миллион тирәсендә мажар бар: боландардан 2 миллионы Румыниядө, 650 мең Словакиядө һәм 350 мең Сербиянең Войводина өлкәсендә яши. Мажарстанда гомуми сайлауларга бер ел калып бара, шуңа күрө «тышкы мажарлар» мәсьәләсе эчке сәяси көрәшнең көндәлек тартталашу төенсенә әйләнде. Бер үк вакытта ул бөтен Аурупаның кызыксынуын уятырлык әһәмияткә дө ия, чөнки аны Югославия фажигасеи күләгәдә калдырырлык бер көйрәп ятучы хәвеф дип санарга мөмкин. Төп ватаннарыннан читтә яшәгән мажарларны аннан кысрыклап чыгару сәясәте уздырылмаса да, халыкларны бер-берсенә каршы көтырту, заманында дөүләт чиклөренең дерес билгеләнмәвеннән калган үпкөлөр, Австрия — Мажарстан империясе дәверендәге мажар хакимияте тарафыннан эшләнгән гадәлсезлекләрнең әле дө хәтердән җуелмавы — болар барысы да дөньяга югослав вакыйгаларының өрәген ачык итеп күз алдыбызга бастыра.

* * *

43 яшендәге Габор, серб гаскәри хезмәтенә чакыру алгач, башына суккандай була. Шунда ук Будапештка качып китүне ниятләп куя. Войводинада (халкы — 2 миллион) туган, милләте мажар Габор туган жиренде уңышка ирешергә жыенган була. Нови Сад жирле телевидениесендә олкән редактор сыйфатында тыныч кына эшләп ятканда, «серблаштыру» сәясәте нәтиҗәсендә, вазифасыннан алына. Шуннан соң ул мажарча айлык журнал чыгарырга керешә. Войводинадагы мажарларның хәлен Габор болай тасвир итә: «Хезер монда «йомшак» диктатура хөкем сөрә. Мажарларны көчләп серб гаскәренә алу аларны кысрыклауның бер төре генә. Безгә бөтенләй кирәксез сугышта туп азыгы булырга теләмәсөк, бердәнбер чарабыз — моннан күчеп китү». Серб армиясенә бармас өчен бүгенгә кадәр 30 мең мажар Югославияне ташлап китереп чыгарга алуын ул бик яхшы белә. «Бу өлкә чын мәгънәсендә дары тулы бер мичкә кебек. Аллага шөкер, өлегә хәтле берәү дә бу мичкәгә үт төртергә жөрьәт итмәде», ди ул. Әмма коммунист атаманнарының берсе, соңынан үзен словак милләтенең Жанна д,Аркы сыйфатында күрсәткән премьер-министр Владимир Мечиар Будапештның Словакияне бүлгөләргә телөвен гаеплөп, болай ди: «Словакия мажарлары Аурупада иң яхшы шартларда яшәгән азчылыклардан берсе. Әмма бу азчылык Мажарстандагы вакыйгаларга муафыйк рәвештә фикерен үзгәртен тора». Тышкы эшләр министры Милан Кначко исо: «Хөкүмәтебез милли азчылыкларның мәдәни үсешларен яклый. Шул ук вакытта Словакиянең бүлгәләнүенә сәбәп булa алырлык автономия көру төлөкләренә унай карамый-быз», дип, мәсьәләгә карашын узган июнь аенда белдергән иде. Будапешт хөкүмәте, жавап рәвешендә, Словакияне Аурупа шурасына (советына) алдыртмаска тырышса да, уңышка ирешмәде.

Словакиядө нөшер ителгән «Республика» гәзите жирле мажарларны «чегәннәр» дип атый. Братиславада ешлыкны шундый хәлләргә юлыгып булa: автобусларда үз телләренде сөйләшө башлаca, словак милләтчеләре мажарларны: «Словакиядә словакча сөйләшөләр», дип искәртергә тотына. Әмма шунысы да чынбарлык: мажар хөкемдарлары кара-каршы дошманлыкны, киненә арттыруда зур роль уйнаган. Азатлык турында йөз илле ел хыялланган Словакия аңа бары тик 1993 елның 1 гыйнварында гына ирешә алды. Словакларның мәдәни йөзләре, кемлекләре башта чех, соңыннан мажар хакимияте тарафыннан таныл-мый киленде.

Словаклар белөн мажарлар тығыз аралашып яшәгән урынларда иңиндидер житди милли каршылыклар килеп чыкмый, әмма словакларның зур күпчелек тәшкил иткән жирләрдә мажарларга мөнәсәбәт яхшыдан түгел. Жәмәгатьчелек фикерен тикшерү нәтиҗәләре аларның 51 проценты, мажарлар үз дәүләтләренә кайтып китсен, дигән телөктә торуын күрсәтте.

* * *

Трансильвания (Румыниянең бер өлеше) башкаласы Клуж шәһәрендәге Кафедрал чиркәү мәйданында король Матиаш һәйкәле бар. Озак еллардан бирле кыйммәтле тарихи истәлек буларак дәүләт тарафыннан саклана. «Гадел Матиаш» кушаматы белөн мәшһүр бу патша, тумышы белөн аксояк бер румыйн улы булса да, 15 йөздәге мажар король-ләренең халык тарафыннан иң сөелгәннәренең берсенә әйләнгән, румыйн белөн мажар каверемнәре арасында дуслыкны нығыткан. Шуңа да карамастан, Клуж шәһәре идарәсенең хәзерге рәисе, чамасыз милләтче Георге Фунар, король Матиаш һәйкәле нигезенә, бу каһарман һәм жиңү белмәс кешенең фәкать румыйннардан жиңелүен аңлатуы бер плакат ябыштырып, ике халык арасына дошманлык орлыгын чәчкән. Халкының 25 процентын мажарлар хасил иткән шәһәрдә бәрәз сонрак алар телендә язылган игъланнар асуны тыйган, мәктәпләрдә мажарча укытуны чиклөгән, рәсми урынларда хакыйкый мажар телендә сөйләштермәс өчен, кулынnан кәгазьнәре барысын эшләгән. Шовинист Чаушескуның бер сыңары шикелле кылланган Фунар, «Һәйкәл сугышын» дәвам иттерен, Клужның башка бер мәйданында румыйн каһарманы Авram Иапкуның 30 метр биеклегендәге бер таш сынын ясатып куйган.

Мажарстан тышында иң зур мажар азчылыгы Румыйниядө яши. Әмма аларның хәллөре башка дәүләтләрдәге милләттәшләренекенә караганда күпкә авыррак.

(Башы 2 биттә)

Ватанын үзенчә — мәгърифәтчеләрчә сөя иде, социалистик идеологиягә кабул итмәгән көе, ул ватанчы буларак ижат итте. Соңрак Ф. Көрими үзенең ул чордагы карашларына тукталып, болай дип язды: «Октябрь революциясенең элек мин милләтчe идем: патша хөкүмәтенең, башка милләтләр шикелле, татар-башкорт халкын кысу һәм изүенә мин милләтчелек, динчелек платформасында торып каршы көрөнә идем. Ул вакытта яшәгән моһәммәт Мәһдиев

ФАТИХ КӘРИМИНЕҢ «ИСТАНБУЛ МӘКТУПЛӘРЕ»

хитыбыз, алган тәрбиябез һәм ул вакыттагы шартлар мине шулай иткән» («Эшче». газ. 1930, № 20). Күргәнебезчә, Баликаннардагы дипломатиянең кабылаулы көрәшенә бәя биргәндә Ф. Көрими нәмуслы, объектив булырга тырышкан. Әлбәттә, аның язмаларында чиклөнгәнлек тә сизелә. Беренче Бөлкән сугышы, анда төхет ияләре нәселенең һәм балкан буржуазиясенең милләтчелек мөнфәгатьләре катнашкан булуга карамастан, прогрессив роль уйный. Тарихта ул сугыш Азиядәге һәм Көнчыгыш Европадагы уртагасырчылыкның һөлакәтен күрсәткән дөньякүләм вакыйгалар чылбырындагы бер бөжра, дип бәяләнә. Шулай да, төреклөрне кызгана-кызгана яза башлаган хәбәрче үзенең субъектив карашларын язмаларында конкрет сүрәтләр белөн күмеп ташлый. «Истанбул мәктупләре»нең авторы катлаулы көрөшләрнең эчке сәбәпләрен ачыклый алмый, аларны шөкер, өлегә кадәр бер бөжра, дип бәяләп, Шулай да, төреклөрне кызгана-кызгана яза башлаган хәбәрче үзенең субъектив карашларын язмаларында конкрет сүрәтләр белөн күмеп ташлый. «Истанбул мәктупләре»нең авторы катлаулы көрөшләрнең эчке сәбәпләрен ачыклый алмый, аларны шөкер, өлегә кадәр бер бөжра, дип бәяләнә. Шулай да, төреклөрне кызгана-кызгана яза башлаган хәбәрче үзенең субъектив карашларын язмаларында конкрет сүрәтләр белөн күмеп ташлый. Тарихта ул сугыш Азиядәге һәм Көнчыгыш Европадагы уртагасырчылыкның һөлакәтен

Трабзон (Заман)

СӘУДӘ ВӘ КАНУН

— Кырык тартмачылар сәүдәсе кануни түгел,— ди Карадингез техника университеты галимнәре Госман Пәһлеван. — Ул ил икътисадына күп зарар китерә.

Мәсьәләне тикшергән Пәһлеван кырык тартмачылыкның берьяклы булуына, аның канунларыбызга каршы килүенә басым ясап: «Бөтен илгә жәелгән бу афәт канунга сыйммый. Читтән беренчө кофе чыныягы алып кайтып милләтәшләребезнө, «бу — контрабанда», дип дәүләт зинданнарга утырта. Ни өчен соң өлө бүген ватанныбызны чит ил кырык тартмачылары ташкынны күмеп китте дә аларга бернинди жөза юк? Белүемчө, кануннар жиелмасында бу мәсьәләгә карата өлө һичнинди үзгәреш кертелмөгән. Гамөлдәге канун жыелмасына карганда, чит ил кешеләре дө, читтән ватанныбызга кайтучы милләттәшләребез дө «шөхси өйберләр», ягъни сөяхәт вакытында көнлек ихтыяжларны канәгатьләндерү өчен кулланыла торган нәрсәләр белөн бераз бүләктән тыш бер товарны да Төркиягә салымсыз кертә алмый. Алмания һәм башка Аурупа дәүләтләренде эшләүче ватандашларыбыз ел саен илебезгә 2,5 миллиард доллардан күбрәк валюта китерө, шул ук вакытта алып кайткан өйберләренең бер өлешне («шөхси милләктән башкасы) тамгачылык келәтләренде калын череп ята. Эшче төреклөр Капыкулөдән (Төркиянең Болгария чигендәге тамгачылык нокгасы) кергәндә тентелөп яткында, румыйн туристлары шул капкадан, элекке Сөветлар Берлгесе ватандашлары исә Сарп чик капкасынан биштырлөре, чемоданнары тулы төрледән-төрле товарлар белөн ничек итеп ансат кына узып китө ала икөн соң? Үемча, аларга карата ясалган ташламалар хәттин ашып, илебезнең социаль-икътисади хәлөнө зарар китерө башлады».

Госман Пәһлеван кырыктартмачылык юлы белөн Төркиягә кергән маллардан ни тамгачылык кылөр, ни дө остәмө кыймәт салымы жәлөтөннән зыянган башка файдасы юклыгы хакында сөйләгәндө, «бер ел эчендә Сарп һәм Капыкулө капкасынан 1 миллион 500 мең кеше кера. Боларның үзләре белөн алып килгән малның кыймәтөн исөнкө алсак, кеше башына уртача 5 миллион төрек лирасы туры килө. Шулай итеп, кергөн малларның тулам кыймәтө 10 триллион лира тәшкил итө. Бу 10 триллионлык товар күләмөненөн ни азы 5 триллионлыгына салым салынмый», дип өйтте.

Аңлатхан хәллөрнең социаль ягына да кагылып үткән Пәһлеван, Төркиягә «кырык тартмачы» сыйфатында килгөн Көнчыгыш туристларының өчтән берсе хатын-кыз икөнен, алардан да күбесенең фәхишәлек кылыр өчен килгөнөнөрен сөйләдө. Әлегө кырык тартмачылар һичбер салым түләми һәм чыгым ясамыйча тына күп табышка ия була, шуның белөн галемдә «Төньяк Европа» дигән ил дә юк диярлек, нәтиҗәдә ватандашларыбыз авыр хәлгә төшө.

Госман Пәһлеван шөһар идарәләренең вак сәүдәгәрләргә яты йөз күрсәтүләрен тәнкыйтьлөп, болай дидө: «Шөһәр идарәләребез, жирле сатучыларга ярдәм итмәгән хәлдә, румыйн һәм урыс туристлары өчен ябык махсус базар урыннары бирө, килмешәклөр базарларда сукыр бер тиен салым түләмөстән, турыдан-туры сату эше белөн шөгыльлөнөп».

Хакан ИНҖӘ

Рәшат НУРИ ГӨНТӘКИН

ГЫЙШЫК ХАТЛАРЫ

(Башы 2 биттә)

батман иде... Әлле инде, балачактагы көбек, ниптөшләргөз белөн сугышкан идегезмө? Йө үзен уңайсыз хәлдө калдырырмын, дип яныгызга килергә бәзмадым».

Рәсим, моны белгөч, чынлап та хафага төште. Моннан соң инде ул гел нөхтө киненөй йөргөргә тырышты.

Бөдия нөуботтәге хатларының берсендө аны мөктөптөн туп-туры өенә кайтмавы, төнгө кадөр ары-бире урамда бутаклыш йөрүе өчен шелтәләгән иде. Әлле ул, Бөдия аның өчен аһ итеп утырганда, башка кызларны озатып йөрүме?

Рәсим, дөньяда Бадияден башка берәүне дө сөймәячәгенө ант итеп, сөекләсенө кайнар хисле хат язып салды, шуннан соң ул урамда очраган кызларга күз кырые белөн карарга да базмый башлады.

Бер кичне Рәсимнең анасы Нөдимә ханым иде Әхмәт бөйне кайтылы бер чырай белөн каршылады һәм слак тавыш белөн:

— Аһ, бөем, башыбызга нинди бөла төшүен дө чамаламыйсың лабаса, син,— дидө.— Бадия исемле нинди-ндер бер жилбәзәк кыз улыбызны үзенө өйләндерергә маташа лабаса. Рәсимнең бүлмөсен жыештырганда шул фетнөнең бер көлтә хаты килеп чыкты. Балабыз кулдан ычкынса... Бер чара табарга кирәк. Фәкать алла хакына, артык мавыгып китмө. Бер кызын китсөн, чаманы төмам онытасың...

Әхмәт бөй исө кызын китәргә уйламады да. Киресенчө, кет-кет көлеп жибәрдө. Аннары пышылдауга күчеп:

— Курыкма, хатынкаем,— дидө.— Улыңа жибөзөк гыйшык хатларын язучы гонаһлы бөндә мин ул! Улыбызның ялкаулыгы көнләп түгел, сәгатьләп арта башлаган иде. Күпме генө тырышсак та, ни мөктөптә укытучылары, ни мин аны һич югы хатасыз язу язарга да өйрәтә алмый тинтерөгөн идек. Уйладым, уйладым да менө шушы хөйләне уйлап таптым. Рәсимебез сөйгөн кызына хатлар текердөтеп, яңа алфавитны әйбөт үзләштерөчөгенө, быел нөуботтәгө сыйныфына да күчәчәгенө бер дө икөлөнмим хәзер. Дөресен әйткөндө, мин үзем дө заманында сина хатлар яза-яза остарып киттем ич!

Төркчәдән Т. РАМАЗАН
тәрҗемәсе.

Сөләймания мәчетенең вәкъфиясенә (вәкыф салган малның документы) караганда, аның 275 хезмәтчесе булса. Алар императорлык дәверендә һәммәсе шул эшендә сакланылганнардыр, дип уйлыйм. Бүген мәчеттә икс имам, биш мөэзин, бер назир (опекун) һәм бер бакчачы — барысы түгыз кеше бар.

Сөләймания. Олы гыйбадәтханә. Дөнья исөн-имин чакта шуның иҫе тагын бөрәр бина төзелерме? Ул бөек кешеләр һәм ул «мәһабәт» дәверләр яңә килсә, бәлки. Өметсез шәйтан бит...

ZAMAN

Адресыбыз: хатлар өчен — 420066, Казан ш., а/я 69. Килөр өчен — Казан ш., Декабристлар ур., 2. 4 кат. Телефоннар: 53-34-45, 53-07-69

Гамәлгә куючысы — **Төркиянең «ЗАМАН» гәзите.**
Хуҗасы — **Алөэттдин КАЯ**
Генераль директоры — **Нажи ТОСУН**
«Заманның Татарстан мөдире — **Муаммәр МОРАТ**
Мөхәррир — **Төфикъ ӘЙДИ**
Хәбәрләр һәм реклама бүлеге мөдире — **Мостафа ПАЛАБОЕК**
Кадрлар бүлеге мөдире — **ЖӘГЪФӘР Садыйк ЧОБАНКАЯ**
Төрҗемә бүлеге мөдире — **Рәшат КАДЫЙР**
Татарстан гәзит-журналлар басмаханөсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Заказ — 7000
Тиражы — 4000 данә.
«Заман» Татарстан Жөмһүрияте мәгълүмат һәм матубгат министрлыгында 246 сан белөн төркөлдө.
Индексы: 54155.
Басарга җул кую вакыты — 18 сәгатьтө.
Басарга җул куелды — 18 сәгатьтә
Һәр язма өчен калөм хакының иң өзө — 1 мең сум.
Язмаларны редакция белөн килешүсез күчереп басу тыела.
Авторларның фикере редакция фикере белөн туры килмәскә дө мөмкин.